**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 февраль № 80

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге» дәүләт казна учреж-дениесен оештыру турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1143 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1143 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта «141,5» һәм «70» саннарын тиешенчә «126,5» һәм «55» саннарына алыштырырга;

6 нчы пункттагы «Инвалидларга һәм ветераннар арасындагы гражданнарның аерым категорияләренә социаль яклау чараларын күрсәтү, шулай ук медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү һәм шәһәрара транспортта дәвалану урынына түләүсез бару һәм аннан кире кайту рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тапшыру турында Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасындагы килешүне» сүзләрен «Инвалидларга һәм ветераннар арасындагы гражданнарның аерым категорияләренә социаль яклау чараларын күрсәтү, шулай ук медицина күрсәткечләре булганда төп авыруларны профилактикалау максатларында гамәлгә ашырыла торган шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү һәм шәһәрара транспортта дәвалану урынына түләүсез бару һәм аннан кире кайту рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү буенча

Россия Федерациясе вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тапшыру турында Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасындагы килешүне» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\80.doc